# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче Сатыш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17.09.2022 № 4

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып, «Сез 2023 нче елда Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче Сатыш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Сатыш авылы территориясендә контейнер мәйданчыклары урнаштыру;
- Сатыш авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунтны эшләү, ком нигезен урнаштру,вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, сууткәргеч торбаларны җиһазлау,килешү буенча эшләр өчен түләү) дигән сорау буенча 2022 елның17 сентябендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 475 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 250 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 250 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче Сатыш торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре - чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2023 нче елда Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче Сатыш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Сатыш авылы территориясендә контейнер мәйданчыклары урнаштыру;

2) Сатыш авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунтны эшләү, ком нигезен урнаштру,вак таштан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбаларны җиһазлау,килешү буенча эшләр өчен түләү), карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/satish адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Сатыш авыл
җирлеге башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНН 1635001023
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САТЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ